ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ
КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

16 апрель, 2015 Казан шәһәре № 42

Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законны үтәү максатында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат биргән өчен түләү алу кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүнең якынча тәртибен раслау турында» 2012 елның 8 декабрендәге 1068 номерлы карары нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Кушымтада бирелүче Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ф. Сафиуллин

Татарстан Республикасының
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең 2015 елның 16
апрелендәге 42 номерлы боерыгы
белән расланды

**МӘГЪЛҮМАТТАН ФАЙДАЛАНУЧЫГА АНЫҢ ГАРЫЗНАМӘСЕ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ТӘРТИБЕ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законны үтәү максатында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат биргән өчен түләү алу кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүнең якынча тәртибен раслау турында» 2012 елның 8 декабрендәге 1068 номерлы карарына туры китереп эшләнде һәм мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү процедурасын билгели.

1.2. Әлеге Тәртип максатларында кулланыла торган төп терминнар һәм билгеләмәләр:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – Инспекция) эшчәнлеге турында мәгълүмат – Инспекция тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә, аның территориаль органнары, аның ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан булдырылган яисә күрсәтелгән органнарга яисә оешмаларга килгән Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүмат (белешмәләр) (шул исәптән документлаштырылган) (алга таба – мәгълүмат).

Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүматка шулай ук Инспекциянең структурасын, вәкаләтләрен, аның эшчәнлеген формалаштыру тәртибен һәм эшчәнлеген билгеләүче, аның эшчәнлегенә кагыла торган закон һәм бүтән норматив хокукый актлар да карый;

2) мәгълүматтан файдаланучы – Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүмат эзләүче гражданин (физик зат), оешма (юридик зат), дәүләт органы, җирле үзидарә органы, иҗтимагый берләшмә;

3) гарызнамә – мәгълүматтан файдаланучының телдән яисә язмача формада, шул исәптән электрон документ рәвешендә, Инспекциягә яисә аның вазыйфаи

затына килгән, Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү турында мөрәҗәгате.

## 2. Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе нигезендә мәгълүмат бирү тәртибе

2.1. Мәгълүматтан файдаланучының ихтыяры буенча сорала торган мәгълүмат аңа телдән яисә документлаштырылган мәгълүмат формасында, шул исәптән кәгазь документ рәвешендә почта аша яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.

2.2. Инспекциягә язмача формада килгән гарызнамә килгән көненнән башлап өч көн эчендә теркәүгә алынырга тиеш. Телдән төзелгән гарызнамә, килгән датасын һәм вакытын күрсәтеп, килгән көнендә теркәлергә тиеш.

2.3. Гарызнамә теркәүгә алынган көненнән соң утыз көнлек чорда Инспекция тарафыннан каралырга тиеш, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса.

Әгәр сорала торган мәгълүматны күрсәтелгән чорда бирү мөмкинлеге булмаса, гарызнамә теркәлгән көннән соң җиде көн эчендә Инспекция мәгълүматтан файдаланучыга гарызнамәгә җавап бирүне кичектерү турында, аның сәбәпләрен һәм сорала торган мәгълүматны бирүнең гарызнамәгә җавап бирү өчен әлеге Тәртиптә билгеләнгән чордан унбиш көннән артып китә алмый торган чорын күрсәтеп, хәбәр итә.

2.4. Инспекция, мәгълүматтан файдаланучыга Инспекция эшчәнлеге турында кирәкле мәгълүмат бирү максатларында, гарызнамәнең эчтәлеген тәгаенләргә хокуклы.

2.5. Мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүмат гарызнамә җавап рәвешендә бирелә, анда сорала торган мәгълүмат бәян ителә яисә аңа теркәлә, яисә, әлеге Тәртипнең 2.11 пунктына туры китереп, күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту бәян ителгән була.

Гарызнамәгә җавапта Инспекциянең аталышы, почта индексы, җавапны имзалаган вазыйфаи затның вазыйфасы, шулай ук гарызнамәгә җавап реквизитлары (теркәүгә алыну номеры һәм датасы) күрсәтелә.

Гарызнамәгә җавап Инспекциядә билгеләнгән тәртиптә теркәүгә алына.

2.6. Мәгълүмат түләүсез яисә түләүле нигездә, сорала торган мәгълүматның күләменә һәм форматына карап, шул исәптән сорала торган документларның һәм (материалларның) күчермәләрен әзерләү һәм бер урыннан икенче урынга җибәрү чыгымнарын исәпкә алып, мондый мәгълүматны бирү тәртибен регламентлаучы законнарга туры китереп бирелә.

2.7. Мәгълүматтан файдаланучыга түләүсез нигездә түбәндәге мәгълүматлар бирелә:

1) телдән тапшырыла торганнары;

2) Инспекция тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен

билгеләнгән урыннарда урнаштырыла торганнары;

3) мәгълүматтан файдаланучының хокукларына һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәнфәгатьле бурычларына кагыла торганнары;

4) Инспекция эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән башка төрле мәгълүмат.

Мәгълүмат тапшырган өчен түләү алу шартлары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы карары белән расланган Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат биргән өчен түләү алу кагыйдәләрендә билгеләнгән.

Әгәр законнар нигезендә мәгълүмат бирү өчен түләү алынмаса, Инспекция мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматны гарызнамәгә туры китереп, әлеге Тәртипнең 2.3-2.5 пунктларында каралган тәртиптә бирә.

2.8. Әгәр законнар нигезендә гарызнамә буенча мәгълүмат тапшырган өчен түләү алу күздә тотылса, Инспекция:

гарызнамәне теркәүгә алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көнлек чорда бу хакта, сорала торган мәгълүматның күләмен һәм форматын, шул исәптән, түләү алына торган мәгълүмат күләмен күрсәтеп, күрсәтелгән түләүне хисаплап, өстәмә чыгымнарны да кертеп, мәгълүмат алу өчен түләү күчерү буенча түләү документын тутыру өчен кирәкле түләүләрнең һәм мәгълүматларның күләмен күрсәтеп, мәгълүматтан файдаланучыга мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча хәбәр итә;

түләү турында раслама алганнан соң мәгълүматны мәгълүматтан файдаланучыга әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында каралган тәртиптә, әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән чорда бирә.

2.9. Мәгълүматтан файдаланучы мәгълүматны кәгазьдә яисә компьютер тупланмасы җайланмасына турыдан-туры Инспекциядә алырга теләсә, ул вакытта Инспекция, әлеге Тәртипнең 2.8 пунктында билгеләнгән чорларга туры китереп, гарызнамәгә җавапта мәгълүматтан файдаланучыга сорала торган мәгълүматның кайсы структур бүлекчәсеннән һәм андагы вазыйфаи заттан алынырга тиешле турында, структур бүлекчәнең адресын, телефонын, эшләү режимын яисә кабул итүнең төгәл датасын күрсәтеп, хәбәр итә.

Әгәр бу максатларда Инспекциядә махсус кертү режимы билгеләнгән булса, мәгълүматтан файдаланучыга бирелгән җавапта бу хакта шулай ук мәгълүмат җиткерелә.

Әгәр мәгълүмат биргән өчен түләү алына икән, ул вакытта мәгълүматтан файдаланучыга бирелә торган мәгълүмат аңа турыдан-туры Инспекциянең мәгълүмат бирү өчен җаваплы булган вазыйфаи затына түләү турында квитанция күрсәтелгәннән соң бирелә.

2.10. Төгәл булмаган белешмәләрдән торучы мәгълүматны биргән Инспекция түләүсез нигездә, мәгълүматтан файдаланучының язмача гаризасы нигезендә, ул дәлилләнгән булырга тиеш, булган төгәлсезлекләрне юкка чыгарырга тиеш.

2.11. Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү мөмкинлеген юкка чыгара торган нигезләр:

1) гарызнамәнең эчтәлеге Инспекция эшчәнлеге турында сорала торган мәгълүматны билгеләү мөмкинлеген бирмәгәндә;

2) гарызнамәдә гарызнамгә җавап бирү өчен почта адресы, электрон почта адресы яисә факс номеры яки гарызнамәне җибәргән мәгълүматтан файдаланучы белән элемтәгә керү өчен телефон номеры күрсәтелмәгәндә;

3) сорала торган мәгълүмат гарызнамә килгән Инспекция эшчәнлегенә кагылмаса;

4) сорала торган мәгълүмат әйләнеше чикләнгән мәгълүматка караса;

5) сорала торган мәгълүмат элегрәк мәгълүматтан файдаланучыга тапшырылган булса;

6) гарызнамәдә Инспекциядә кабул ителгән актларга хокукый билге бирү, аның, территориаль органнарының яисә ведомство буйсынуындагы оешмаларының эшчәнлегенә анализ үткәрү яки башка төрле, гарызнамәне юллаган мәгълүматтан файдаланучының хокукларын яклауга турыдан-туры бәйле булмаган аналитик эш уздыру мәсьәләсе куелган булса.

Әгәр Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган булса яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган булса, Инспекция бу мәгълүматны бирмәскә дә хокуклы. Бу очракта гарызнамәгә җавапта Инспекция сорала торган мәгълүмат урнаштырылган массакүләм мәгълүмат чарасының аталышын, чыгу датасын һәм номерын һәм яисә сорала торган мәгълүмат урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресын күрсәтү белән генә чикләнә.

2.12. Әгәр гарызнамә үзе юлланган Инспекция эшчәнлегенә кагылмаса, ул вакытта Инспекциядә гарызнамәне теркәүгә алган көннән соң җиңе көн эчендә, ул сорала торган мәгълүматны бирүгә вәкаләтле булган дәүләт органына яисә җирле үзидарә органына җибәрелә. Гарызнамәнең икенче урынга юллануы турында шул ук чорда гарызнамәне җибәрүче мәгълүматтан файдаланучыга да хәбәр ителә.

Әгәр Инспекциядә сорала торган мәгълүматның башка дәүләт органында яисә җирле үзидарә органында булу-булмавы турында белешмәләр булмаса, бу хакта шулай ук гарызнамәне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә гарызнамәне җибәрегән мәгълүматтан файдаланучыга хәбәр ителә.

2.13. Әгәр сорала торган мәгълүмат әйләнеше чикләнгән мәгълүматка караса, гарызнамәгә җавапта әлеге мәгълүматтан файдалануны чикләүгә нигез булган актның төре, аталышы, номеры һәм кабул ителү датасы күрсәтелә. Әгәр сорала торган мәгълүматның бер өлеше әйләнеше чикләнгән мәгълүматка караса, ә калган өлеше гомуми файдалану өчен яраклы булса, Инспекция әйләнеше чикләнгән мәгълүматтан кала, сорала торган мәгълүматны бирә.

2.14. Гарызнамәне төзегәндә мәгълүматтан файдаланучы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләреннән файдалана.

2.15. Гарызнамә чит телдә килгән очракта, Инспекциянең Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүмат бирү өчен җаваплы булган вазыйфаи заты аның рус теленә тәрҗемә ителүен тәэмин итә. Гарызнамәне алга таба карау 2.1-2.14 пунктларында каралган тәртиптә гамәлгә

ашырыла.

## 3. Мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүне тикшереп тору тәртибе

3.1. Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне Инспекция башлыгы тикшереп тора.

3.2. Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне агымдагы контрольлектә тоту Инспекция башлыгының тикшереп торыла торган юнәлешләрдәге урынбасарлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматның тулы, актуаль һәм төгәл булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрүне, мәгълүмат җиткерү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне үз эченә алучы мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүләрне, алар буенча карарлар һәм җаваплар кабул итүне үз эченә ала.

3.3. Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

3.4. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, Инспекциянең Инспекция эшчәнлеге турында мәгълүмат алуны бозуда гаепле вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.